ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ПЕЧИЩИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
Ул. Декабристов, д.35 а, с. Печищи, 422592

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮГАРЫ ОСЛАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ ПЕЧИЩИ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
Декабристлар ур., 35 нче йорт, Печищи авылы, 422592

Тел.: (84379) 2-29-44, факс: (84379) 2-29-44.

__________________№________________

На №______________от________________

КАРАР

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Печище авыл җирлеге Печище торак пункты территориясендә гражданнар җыенының 2023 елның 4 декабрендәге 1 номерлы карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә «Югары Ослан муниципаль районының Печище авылы җирлеге Печище торак пункты территориясендә гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2023 елның 4 декабрендәге 1 номерлы гражданнар җыены карарына үзгәрешләр кертү һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерү белән сез килешәсезме?-торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Печище авылы Исаев урамы буенча эчке юлларны ремонтлау) дигән мәсьәлә буенча 2024 елның 12 апрелендә узган гражданнар җыены нәтиҗәләре белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде.

«ӘЙЕ» «ЮК»

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:
Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә 3 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны 3 кеше.
Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:
«Әйе» позициясе өчен гражданнар җыенының 3 катнашучысы тавыш бирде; «Юк» позициясе өчен җыенның 0 катнашучысы тавыш бирде, тыелып калдылар - җыенның 0 катнашучысы.
Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1. Югары Ослан муниципаль районының Печище авылы җирлегенең Печище торак пункты территориясендә гражданнар җыенын узган, халык җыены нәтиҗәләре - дөрес дип танырга.

2. «Югары Ослан муниципаль районының Печище авылы җирлеге Печище торак пункты территориясендә гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2023 елның 4 декабрендәге 1 номерлы гражданнар җыены карарына үзгәрешләр кертү һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерү белән сез килешәсезме?-торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Печище авылы Исаев урамы буенча эчке юлларны ремонтлау) дигән мәсьәлә буенча карарны танырга.

«ӘЙЕ» «ЮК»

3. Печище авылы җирлегенең Печище торак пункты территориясендә халык җыенының нәтиҗәләрен Печище авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында игълан итәргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Печище авыл җирлеге башлыгы урынбасарына ТР муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Җыелышта рәислек итүче: Г.В.Полякова